КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 сентябрь г.Казань № 965

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1642 номерлы карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында 2022 – 2026 елларда Татарстан Республикасында мәгарифнең мәктәп системаларын модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1642 номерлы карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасындагы мәгарифнең мәктәп системаларын модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру кысаларында капиталь ремонт ясау, белем һәм тәрбия бирүнең заманча чаралары белән җиһазландыру юлы белән гомуми белем бирү оешмалары биналарын норматив хәлгә китерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «2022 – 2026 елларда Татарстан Республикасында мәгарифнең мәктәп системаларын модернизацияләү» Татарстан Республикасы төбәк проектын расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын «2022 – 2026 елларда Татарстан Республикасында мәгарифнең мәктәп системаларын модернизацияләү» Татарстан Республикасы төбәк проекты чараларын гамәлгә ашыру буенча төбәк координаторы итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин